**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 август № 565

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 гыйнвар, 9 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«рәис урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеген боерыгы белән раслый;

Дәүләт комитетына беркетелгән процессларны (ярдәмче процессларны) үтәү стандартларын боерыгы белән раслый;

эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә рәис урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында нигезләмәне, шулай ук эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән күрсәткечләренә бәйле стимуллаштыручы түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү турында нигезләмәне боерыгы белән раслый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков